Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы

# Б О Е Р Ы К

2014 елның 20 августы Казан ш. № 164/2-пр

Ведомство максатчан программасын һәм ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Россия Федерациясе субъектларының авыл хуҗалыгын үстерү буенча икътисадый әһәмиятле региональ программаларына ярдәм итү очен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бүлү һәм бирү кагыйдәләрен раслау турында” 2010 елның 17 декабрендәге 1042 номерлы карары нигезендә

б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымта итеп бирелгән түбәндәге ведомство максатчан программасын расларга:

“2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ябык грунт яшелчәчелеген үстерү” (1 нче кушымта).

2. Ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга 2014 елда субсидияләр бирү буенча кушымта итеп бирелгән түбәндәге тәртипне расларга:

“2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ябык грунт яшелчәчелеген үстерү” ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә аларның чыгымнары өлешен каплауга 2014 елда субсидияләр бирү тәртибен (2 нче кушымта);

3. Тапшырылган документларның дөреслеге, бюджет акчаларының максатчан тотылуы очен җаваплылыкны субсидияләрне алучыларга, авыл хуҗалыгы оешмаларының җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләргә.

4. Бюджет алучы тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген тикшерүне һәм раслауны Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба – Министрлык) Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре башлыкларына йөкләргә.

5. Министрлыкның игенчелек тармакларын үстерү бүлеге башлыгы В.Л. Новичковка һәм Министрлыкның инвестицияләр сәясәте һәм максатчан

программалар бүлеге башлыгы И.Ш. Гафуровка федераль бюджеттан субсидияләр алу өчен тапшырылган әлеге боерыкның 1 пунктында каралган документларның Министрлыкның игенчелек тармакларын үстерү бүлеге һәм инвестицияләр сәясәте һәм максатчан программалар бүлеге белгечләре тарафыннан кабул ителүләрен тәэмин итәргә.

6. Министрлыкның финанс бүлеге башлыгы М.А. Мәхмүтовка авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә әлеге боерыкта билгеләнгән документларда каралган субсидияләрне үз вакытында бирүне тәэмин итәргә.

7. Бу боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары И.Х. Габдрахмановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

РАСЛЫЙМ
Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры

____________________ М.Г.Әхмәтов

«____»_________2014 ел

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

# “2014 – 2016 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ЯБЫК ГРУНТ ЯШЕЛЧӘЧЕЛЕГЕН ҮСТЕРҮ”

# ВЕДОМСТВО МАКСАТЧАН ПРОГРАММАСЫ

Казан 2014

ЭЧТӘЛЕК

1. “2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ябык грунт яшелчәчелеген үстерү” ведомство максатчан программасының паспорты..........3
2. Программа хәл итәргә тиешле проблемаларга күзәтү .................................. 4
3. Төп максатлар һәм бурычлар ........................................................................ 7
4. Максат индикаторлары ................................................................................ 7
5. Программа чараларының исемлеге һәм тасвирламасы ...................................8
6. Программаның социаль-икътисадый һәм экологик нәтиҗәлелеге..............9
7. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү........................11
8. Программаны тормышка ашыруга идарә итү системасына тасвирлама......12
9. Программаны тормышка ашыру сроклары ...................................................14

# 1. Ябык грунт яшелчәчелеген үстерү программасы
# ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ябык грунт яшелчәчелеген үстерү |
| Программаны эшләү өчен нигез | ТР Министрлар Кабинетының 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары белән расланган “2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу” дәүләт программасы |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаның максаты | Татарстан Республикасында яшелчәләр сезоныннан тыш башка вакытта ябык грунтта яшелчәләр үстерүне арттыру |
| Төп бурычлар | Татарстан Республикасы халкын үзендә үстерелгән ябык грунт яшелчә продукциясе белән тулысынча тәэмин итү;<br>Ябык грунт яшелчәләрен үстерүгә яңа инновацион технологияләрне кертү |
| Программада катнашучылар | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының авыл хуҗалыгы предприятиеләре, теплица хуҗалыклары |
| Программаның төп чаралары | - 35 гектар мәйданда сезоннан тыш башка чорда 28 мең тоннадан артык житештерү күләме булган яңа югары технологияле теплицалар төзү;<br>- кушма егәрлеге 47 мВт/сәг когенерацияле энергия үзәкләрен төзү;<br>- технологик җиһазлар сатып алу. |
| Программаны тормышка | 2014 – 2016 еллар |

| | |
|---|---|
| ашыруның сроклары һәм баскычлары | |
| Программаны үтәүчеләр | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы,<br>Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының авыл хуҗалыгы предприятиеләре (алга таба - АПК). |
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | **Барлыгы – 2 734,0 миллион сум,**<br>шул исәптән:<br>Федераль бюджет – 820,2 миллион сум<br>Бюджеттан тыш чыганаклар – 1 913,8 миллион сум |
| Максат индикаторы һәм программаның күрсәткечләре | - теплицаларның мәйданы – 35 гектар;<br>- ябык грунт яшелчәләрен үстерү күләме - 28,0 мең тонна;<br>- ябык грунт яшелчәләрен сату күләме - 1400,0 миллион сум. |
| Программаны тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр | үстерүнең инновацион технологияләре кулланыла торган яңа теплицаларның мәйданы 35 гектар тәшкил итәчәк<br>сезоныннан тыш башка чорда үстерелә торган ябык грунт яшелчәләрен үстерү күләме 28 мең тоннадан артып китәчәк, 2016 елда Татарстан Республикасында әлеге күрсәткеч 49 мең тоннага кадәр җитәргә тиеш;<br>- электр энергиясенә тарифларны 1,75 кВт/сәг кадәр, җылылык энергиясенә тарифларны 560 сум/Гкалл кадәр төшерү;<br>- ябык грунт яшелчәләрен үстерүне тулы күләмдә үз электр энергиясе һәм җылылык энергиясе чыганаклары белән тәэмин итү. |
| Идарә итү һәм тикшереп тору системасы | Программаны тормышка ашыру өчен тулаем Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы җаваплы |

## 2. ПРОГРАММА ХӘЛ ИТӘРГӘ ТИЕШЛЕ ПРОБЛЕМАЛАРГА КҮЗӘТҮ

2020 елга кадәрге Россия Федерациясенең илкүләм иминлеге стратегиясенең илкүләм иминлекне тәэмин итүнең төп юнәлешләреннән берсе буларак азык-төлек куркынычсызлыгы билгеләнә. Азык-төлек

куркынычсызлыгы доктринасында каралганча, үзебездә үстерелгән ябык грунт яшелчәләре белән тәэмин ителеш кимендә 80 процент булырга тиеш. Азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү очен ябык грунт яшелчәчелеген сезоннан тыш башка чорда яңа үскән яшелчә продукциясенең төп чыганагы буларак үстерергә кирәк.

“2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ябык грунт яшелчәчелеген үстерү” программасы (алга таба – Программа) сезоннан тыш башка чорда ябык грунт яшелчәләрен үстерүне яңа теплицаларда заманча үстерү технологияләрен кулланып арттыруга юнәлтелгән.

Программа “2013 – 2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу” дәүләт программасы кысаларында эшләнде.

**“2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ябык грунт яшелчәчелеген үстерү” программасының күрсәткечләре**

| Күрсәткечләр | 2012 ел факт | 2013 ел факт | 2014 ел | | | 2015 ел | | | 2016 ел | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Булган теплицалар буенча | Яңа төзелгән теплицалар буенча | Барлыгы | Булган теплицалар буенча | Яңа төзелгән теплицалар буенча | Барлыгы | Булган теплицалар буенча | Яңа төзелгән теплицалар буенча | Барлыгы |
| Теплицаларның мәйданы, гектар | 55,5 | 58,5* | 58,5 | 3,6 | 62,1 | 62,1 | 13 | 75,1 | 75,1 | 18,4 | 93,5 |
| Уцыш, кг/кв.м. | 50,4 | 60 | 60 | 80 | 62 | 62 | 80 | 65,1 | 65,1 | 80 | 68 |
| Үстерү, тонна | 27972 | 35669 | 35669 | 2 880 | 38549 | 38549 | 10 400 | 48949 | 48949 | 14 720 | 63669 |
| Сатудан кергән акча, миллиард сум | **1,4** | **1,7** | **1,7** | **0,144** | **1,844** | **1,844** | **0,582** | **2,426** | **2,426** | **0,726** | **3,152** |
| Сатудан кергән акчада артым, процентлар | | **84 яңа тепли-цалар буенча** | **21** | **171** | **8** | **8** | **504** | **31** | **31** | **205** | **30** |

*- 2013 елда 3 гектар яңа югары технологияле теплицалар сафка кертелде

**Вәзгыятькә анализ**

“2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ябык грунт яшелчәчелеген үстерү” программасының төп бурычы кулланучыларны сезоннан тыш чорда (ноябрь-февраль) яңа үскән яшелчә продукциясе белән тәэмин итүдән гыйбарәт. Татарстан Республикасының теплица предприятиеләре ачык грунт яшелчәләрен үстерү чорында да үзләренең җитештерү эшчәнлекләрен туктатмыйлар, чөнки ачык грунтта яшелчәләр үстерү белән шөгыльләнүче хуҗалыклар яшелчәләргә булган зур ихтыяҗны канәгатьләндереп бетерә алмый.

- Базарның үзенчәлекләре: базардагы башка көндәшләр арасындагы өстенлекне билгеләүче “иртә өлгерә торган продукция” белән чыгу – иң мөһим бурыч.

Илдә, тулаем алганда, яңа теплицаларны төзү эше бик акрын темплар белән бара, бу базар мөнәсәбәтләрен үстерү асылына каршы килә.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасының ябык грунт яшелчәчелегендә яңа технологияләр кулланыла торган яңа теплицалар төзүне үз эченә алган төзелеш, реконструкция, модернизация эшләрен башкару һәм технологик җиһазлар сатып алу таләп ителә.

Теплицаларның техник җиһазланышы һәм алардагы конструкцияләрнең тузуы хәзерге чорда җитди проблемага әйләнеп бара. Тармакның нәтиҗәле үсешен тоткарлый торган фактор да, җитештерү мәйданнарыннан түбән нәтиҗәлелек белән файдалануның, хезмәт җитештерүчәнлеге кимүнең сәбәбе дә нәкъ шунда.

Белгечләрнең экспертиза ясаганнан соңгы бәяләмәләрендә билгеләнгәнчә, тулаем Россия Федерациясендә базар шартларында конкуренциядә катнаша алмаган һәм халыкны һәрдаим яңа үскән яшелчә продукциясе белән тәэмин итеп тора алмаган яшелчәләр үстерү теплицаларының саны шактый.

Моннан тыш, шул ук вакытта яңа теплицаларда кулланыла алган зур резерв бар, аңа Татарстан Республикасы халкы ихтыяҗларын сыйфатлырак, шул исәптән сезоннан тыш башка чорда канәгатьләндерү максатыннан

яшелчәләрнең төрле төрләрен елдагы аерым чорлар буенча җитештерүнең иң уңай нисбәтлелеге аша ирешелә.

Әлбәттә, яшелчәләрне тәүлек буе тотрыклы үстерүне тәэмин итүнең мөһим факторы буларак ябык грунт яшелчәчелегенең икътисадый яктан нәтиҗәле системасы уңышлы эшләсен очен яшелчәләр базарын булдыра торган барлык кызыксынулы затларның һәм, иң беренче чиратта, закон чыгару һәм башкарма хакимият органнарының, Россия авыл хуҗалыгы фәннәр академиясе галимнәренең һәм урындагы белгечләрнең уртак көч куюы таләп ителә.

Ябык грунт яшелчәчелеге – авыл хуҗалыгының мөһим тармагы. Ябык грунт яшелчәләрен тулаем җыю буенча Татарстан Республикасы Идел буе федераль округына керүче Россия Федерациясе субъектлары арасында һәм гомумән Россия Федерациясендә алдынгы урыннарның берсен алып тора, шул ук вакытта Татарстан Республикасы Россия Федерациясе субъектлары арасында сезоннан тыш чорда ябык грунт яшелчәләрен үстерү буенча югары баскычны били.

Ябык грунт яшелчәчелегендәге югары нәтиҗәләргә ирешсәк тә, халыкның сезоннан тыш чорда ябык грунт яшелчәләре белән тәэмин ителешенең медицина нормаларына җавап бирмәве проблемасы хәзергәчә Татарстан Республикасы өчен мөһим булып кала бирә.

## 3. ТӨП МАКСАТЛАР ҺӘМ БУРЫЧЛАР

Максат – авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә ябык грунт яшелчәләрен үстерү өчен һәм алар җитештергән продукцияне гарантияләнгән сату өчен, сезоннан тыш чорда үзебездә үстерелгән яшелчәләр белән халыкны тәэмин итүне яхшырту өчен шартлар тудыру.

Билгеләнгән максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

- югары нәтиҗәләр бирә торган һәм инновацион производство өчен кирәкле җиһазлар белән җиһазландырылган теплицалар төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләү;

- республика халкының үзебездә үстерелгән яшелчә продукциясенә ихтыяҗын тармакны инновацион үсеш юлына күчереп тәэмин итү.

## 4. МАКСАТ ИНДИКАТОРЛАРЫ

Программаның төп максат индикаторлары һәм аларныц күрсәткечләре таблицада еллар буенча күрсәтелгән:

**Программаның яңа гына сафка кертелә торган югары технологияле теплнңалар буенча төп максат индикаторлары**

| Күрсәткеч | Исәп берәмлеге | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Теплицаларны төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү һәм технологик җиһазлар сатып алу | гектар | 3 | 3,6 | 13 | 18,4 |
| Куәт , | тонна/ гектар | 800 | 800 | 800 | 800 |
| Сезоннан тыш чорда ябык грунт яшелчәләрен үстерү | тонна | 2 400 | 2 880 | 10 400 | 14 720 |
| Арта бара торган җитештерү күләме | тонна | 2 400 | 2 880 | 13 280 | 28 000 |

## 5. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫНЫҢ ИСЕМЛЕГЕ ҺӘМ ТАСВИРЛАМАСЫ

Ведомствоныц икътисадый әһәмияткә ия 2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ябык грунт яшелчәчелеген үстерү максатчан программасын гамәлгә ашыру өчен программа чаралары комплексы эшләнде.

| Финанслау чыганаклары | Барлыгы, миллион сум | шул исәптән еллар буенча | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Федераль бюджет | 820,2 | 138,4 | 387,8 | 294 |
| Бюджеттан тыш фондлар | 1 913,8 | 322,8 | 905 | 686 |
| **Финанслауның гомуми күләме** | **2 734,0** | **461,2** | **1292,8** | **980** |

Проект 410 кеше очен югары җнтештерүчәнлекле яңа эш урыннарын булдыруны, “2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-толек базарларын җайга салу” дәүләт программасының “Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү” ярдәмче программасы кысаларында авыл җирендә яшь белгечләр өчен торак төзүне күз алдында тота. Теплицалар төзү планлаштырыла торган торак пунктларда мәктәпләр һәм балалар бакчалары бар.

## 6. ПРОГРАММАНЫҢ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ ҺӘМ ЭКОЛОГИК НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕ

Программаны тормышка ашыру Татарстан Республикасында ябык грунт яшелчәчелеген тотрыклы үстерү очен шартлар һәм алшартлар тудырачак, сезоннан тыш чорда яшелчәләр үстерү күләмен арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Программаны тормышка ашыру тармакның тотрыклылыгын һәм конкуренция сәләтлелеген арттыру максатларында аны технологик яңартуны күз алдында тота.

Программаны тормышка ашыруның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген исәп-хисабы таблицада китерелгән (сафка кертелә торган яңа югары технологияле теплицалар буенча).

| Күрсәткеч | Исәп берәмлеге | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2013 елга карата 2016 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Теплицаларны төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү һәм технологик җиһазлар сатып алу | га | 3,0 | 3,6 | 13 | 18,4 | 613% |
| Куәт | тонна/ гектар | 700 | 800 | 800 | 800 | 114% |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Сезоннан тыш чорда ябык грунт яшелчәләрен үстерү | тонна | 2100 | 2 880 | 10 400 | 14 720 | 700% |
| Сатудан кергән акча | миллион сум | 84,0 | 144,0 | 582,4 | 764,0 | 909% |
| Арта бара торган җитештерү күләме | миллион сум | 84,0 | 144,0 | 726,4 | 1400,0 | |
| Сатудан кергән акчадагы артым | процентлар | 84 | 171 | 504 | 205 | |

Татарстан Республикасында ябык грунт яшелчәләрен үстерү күләмнәренең артуы тактик һәм стратегик бурычларның хәл ителешен күрсәтә торган фактор булып тора.

Программаны тормышка ашыру үзебезнең илдә үстерелә торган яшелчәләр продукциясенең конкуренциягә сәләтлелеген арттырырга ярдәм итәчәк, үсемлекчелекнең төп тармакларының берсе булган юнәлешне тотрыклы үстерү өчен шартлар һәм алшартлар тудырачак.

Программаның максат индикаторлары һәм тулы күләмендә финансланганда аның икътисадый нәтиҗәлелеге индикаторлары динамикасына анализ ябык грунт яшелчәләрен үстерү күләмнәрендә зур артымнар булу ихтималын күрсәтә.

Программа буенча югары технологияле яңа теплицалар төзү өчен бюджет акчаларының нәтиҗәле тотылуы исәп-хисабы таблицада китерелгән.

| Күрсәткечләр | Исәп берәмлеге | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 3 елга барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| Яшелчәләрне сатудан арта бара торган кергән акча | миллион сум | 144,0 | 726,4 | 1490,4 | **2360,8** |
| Яшелчәләр сатудан керә торган акчаның еллык артымы | миллион сум | 144 | 582,4 | 764,0 | - |
| Программаны финанслау - барлыгы (Ф) | миллион сум | 461,2 | 1292,8 | 980,0 | **2734,0** |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Нәтиҗәлелек күрсәткечләре - $Э_{общ}$ | процентлар | 31,2 | 56,1 | 152,0 | **86,3** |
| Яңа эш урыннары булдыру | кеше | 47 | 214 | 149 | **410** |

Финанслау акчаларын нәтиҗәле тоту программаның ахыргы нәтиҗәләре һәм аны гамәлгә ашыру чыгымнары нисбәте буенча түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$Э_{общ} = ΔТП/Ф \times 100$,

монда: $Э_{общ}$ - финанс чараларын тотуның гомуми нәтиҗәлелеге коэффициенты;

ΔТП – товар продукциянең бәя ягыннан еллык артымы;

Ф – программа буенча продукция җитештерүне финанслау күләме.

Программаны тормышка ашыру тискәре экологик нәтиҗәләргә китерми, ул игенчелек культурасын яхшырту буенча культура-техник чараларын үткәрү юлы белән төбәкнең табигать ресурсларын торгызуга һәм саклап калуга ярдәм итәчәк.

## 7. ПРОГРАММАНЫҢ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТЕЛЕШЕН НИГЕЗЛӘҮ

Программаны финанслау федераль бюджет акчалары исәбеннән һәм бюджеттан тыш чыганакларның акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырылачак.

Программа буенча планлаштырылган чараларны гамәлгә ашыру очен таләп ителә торган акчаларның күләме технологик җиһазларга һәм теплицаларның конструкцияләренә капитал салуларга экспертлар бәяләмәләрен исәпкә алып хисаплана.

Программа чараларын финанслау күләмнәре һәм чыганаклары буенча исәп-хисаплар һәм башлангыч күрсәткечләр таблицада күрсәтелгән.

**Программа чараларын финанслауга гомуми ихтыяҗ һәм анық чыганаклары, миллион сум**

| Чаралар | Чыганак | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2014-2016 елларга барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| Теплицаларны төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү һәм технологик җиһазлар сатып алу | Федераль бюджет | 138,4 | 387,8 | 294,0 | 820,2 |
| | Бюджеттан тыш акчалар | 322,8 | 905,0 | 686,0 | 1 913,8 |
| | **Барлыгы:** | **461,2** | **1292,8** | **980** | **2 734,0** |

## 8. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУГА ИДАРӘ ИТҮ СИСТЕМАСЫНА ТАСВИРЛАМА

Программа белән комплекслы идарә итү һәм федераль бюджет акчаларын бүлеп бирү эшен бюджетны планлаштыру субъекты – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) башкара.

Программаның гамәлгә ашырылуына идарә итү системасы:

– программаның тулаем гамәлгә ашырылуы, программа максатларына һәм бурычларына, максат индикаторларына, программада расланган бурычлар һәм чаралар күрсәткечләренә ирешү өчен Министрлык җаваплы;

– Министрлык структур бүлекчәләренең һәм Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының программаны тормышка ашыруда катнашучы оешмаларының эшчәнлеген координацияләүне һәм аларның программа чараларын тормышка ашыру буенча гамәлләрен килештерүне Министрлыкның икътисадый анализ һәм планлаштыру бүлеге һәм игенчелек тармакларын үстерү бүлеге башкара;

– программаның һәр чарасын гамәлгә ашыруны һәм программаны тормышка ашыруны Министрлыкның игенчелек тармакларын үстерү бүлеге һәм бу эштә кызыксынулы булган башка бүлекләре башкара;

– программа чараларын финанслауны Министрлыкның финанслау бүлеге башкара;

– программаның гамәлгә ашырылуына мониторингны Министрлыкның игенчелек тармакларын үстерү бүлеге, Министрлыкның икътисадый анализ һәм планлаштыру бүлеге, Министрлыкның агросәнәгать комплексын инженер-техник тәэмин итү бүлеге, Министрлыкның кадрлар бүлеге, Министрлыкның фән, мәгариф һәм инновацион технологияләр бүлеге, Министрлыкның азык-төлек базарын үстерү бүлеге, Министрлыкның инвестицияләр сәясәте һәм максатчан программалар бүлеге, Министрлыкның финанслау бүлеге, Министрлыкның предприятиеләрне реструктуризацияләү һәм агробизнесны үстерү бүлеге уздыра;

– Программаны тормышка ашыру барышы турында хисап төзү өчен Министрлыкның игенчелек тармакларын үстерү бүлеге, Министрлыкның икътисадый анализ һәм планлаштыру бүлеге, Министрлыкның финанслау бүлеге, Министрлыкның бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге җаваплы.

Татарстан Республикасы бюджетының программа чараларын тәэмин итүне финанслаудагы чыгым йөкләмәләренең хокукый нигезләре Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы һәм Татарстан Республикасы арасында соңгыларын Программада катнашучылар исәбенә кертү турында килешүләр төзү нәтиҗәсендә барлыкка килә.

**Программаны тормышка ашыруның куркынычлы якларына бәя бирү**

Планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүгә йогынты ясарга мөмкин төп куркынычлыкларга түбәндәгеләр керә:

а) Тышкы куркынычлыклар:

– дәүләт-хосусый партнерлыгы линиясе буенча инвесторлар ягыннан финанслауның, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренең үз акчаларының һәм заем акчаларының җитәрлек дәрәҗәдә булмавы;

– табигать-климат шартларының начар булуы;

– авыл җире өчен товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр белән бәйле тискәре базар конъюнктурасы (энергия чыганакларына, ашламаларга һ.б.ш.)

б) Эчке куркынычлыклар:

– оештыру эшендәге куркынычлыклар, кадрлар әзерләүнең вакытында башкарылмавы;

– җитештерү һәм технология куркынычлыклары;

Программаны тормышка ашыру кысаларында куркынычлыклар белән идарә итү барлык чыганаклардан да үз вакытында кирәгенчә финанслау һәм технологик регламентларны тогәл үтәү рәвешендә башкарылырга тиеш. Энергия чыганакларына, ашламаларга, авыл очен башка товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә нигезсез югары бәяләргә бәйле булган куркынычлыклар федераль дәрәҗәдә дәүләт тарафыннан идарә ителергә тиеш.

Булырга мөмкин куркынычлыклар исәп-хисабы таблицада китерелгән.

| Куркынычлыклар торләре | План | 2015 ел | 2016 ел |
|---|---|---|---|
| Планлаштырылган уцыш алмау аркасында (кг/кв.м) | 80 | 70 | 70 |
| планлаштырылган җитештерү күләменә ирешмәү аркасында (тонн) | - | 672 | 400 |
| Яшелчәләрне плнлаштырылган үстерә алмау аркасында була торган куркынычлыкларга гомуми бәя миллион сум | - | 35 | 22,4 |

## 9. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ СРОКЛАРЫ

Программа 2014-2016 елларда тормышка ашырыла.

**Программа чараларын тормышка ашыру графигы**

| № п/п | Программаның бүлекләре, чаралар | Башкару очен җаваплылар | Башкару сроклары | Эшләр күләме |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Теплицаларны төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү һәм технологик җиһазлар сатып алу | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 2014-2016 еллар | 2 734 миллион сум |

2014 елның 20 августындагы
164/пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-
төлек министрлыгы боерыгына
2 нче кушымта

“2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ябык грунт яшелчәчелеген үстерү” ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә аларның чыгымнары өлешен каплауга 2014 елда субсидияләр бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип “2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ябык грунт яшелчәчелеген үстерү” ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) аларның яшелчәчелек объектларын төзү, реконструкцияләү һәм ябык грунт яшелчәләрен җитештерүне арттыру өчен җиһазлар сатып алу чыгымнары өлешен каплауга субсидияләр бирү (алга таба – субсидияләр, Программада катнашучылар) тәртибен һәм шартларын билгели.

2 Ябык грунт яшелчәләре үсә торган җир кишәрлекләренең Программада катнашучыларның милкендә булуы яки алар тарафыннан арендага алынуы субсидияләр бирү өчен шарт булып тора.

3. Программада катнашучыларга субсидияләр бирү максаты кулланучыларны яшелчәләр сезонынннан тыш башка вакытта да яңа үскән яшелчәләр белән тәэмин итүдән гыйбарәт.

4. Субсидияләр алу өчен Программада катнашучыларны сайлап алу критериен ябык грунт яшелчәләрен җитештерү һәм сатуга чыгарырга әзерләү тәшкил итә.

5. Программада катнашучылар өчен субсидияләрнең күләме түбәндәгедән чыгып исәпләнә:

- башкарылган һәм түләнгән эшләр күләменнән чыгып, яшелчәчелек объектларын төзү һәм реконструкцияләү чыгымнары өлешен каплауга 80 процент;

- түләнгән җиһазлар бәясеннән чыгып, ябык грунт яшелчәләрен җитештерүне арттыру өчен җиһазлар сатып алу буенча 80 процент.

6. Җиһазлар сатып алу чыгымнары өлешен каплауга субсидияләр алу өчен Программада катнашучылар тарафыннан Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) түбәндәге документлар тапшырыла:

субсидияләр бирү турында гариза, түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп;

җиһаз китерү шартнамәсенең күчермәсе;

җиһаз сатып алуга товар-транспорт накладное күчермәсе һәм (яки), Россия Федерациясендә аналоглары булмаган җиһазларны импорттан керткән очракта, таможня декларациясе күчермәсе;

төп чаралар объектын кабул итеп алу – тапшыру турында актның (ОС-1а формасы буенча) күчермәсе;

түләү йөкләмәсенең, җиһаз өчен түләүне раслый торган банк өземтәсенең күчермәсе;

субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәсе;

тапшырылган документларның күчермәләре – Программада катнашучылар тарафыннан, ә түләү документлары – банклар тарафыннан таныклана.

7. Төзелеш һәм реконструкция чыгымнары өлешен каплауга субсидияләр алу өчен Министрлыкка түбәндәге документлар тапшырыла:

субсидияләр бирү турында гариза, түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп;

башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләре;

төзелә торган объект буенча экспертиза узган җыелма исәп-хисап сметасының күчермәсе;

ябык грунт яшелчәчелеге объектларын төзү һәм (яки) реконструкцияләү эшләрен башкаруга шартнамә күчермәсе;

эшләрне кабул итеп алу турында КС-2 формасы буенча актларның, башкарылган эшләрнең хакы һәм чыгымнарның бәясе турында КС-3 формасы буенча белешмәләрнең күчермәләре;

субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәсе;

тапшырылган документларның күчермәләре – Программада катнашучылар тарафыннан, ә түләү документлары – банклар тарафыннан таныклана.

8. Министрлык:

а) субсидияләр бирү соралган гаризаларны алар алынган көнне журналга терки, ул номерланган, шнурланган һәм мөһер сугылган булырга тиеш;

б) әлеге Тәртипнең 6 һәм 7 пунктлары нигезендә тапшырылган документларны карый, документларны карау срогы субсидияләр бирү соралган гаризаны теркәгән көннән алып 20 календарь көннән күбрәк булырга тиеш түгел;

в) Программада катнашучыларга әлеге Тәртипнең 6 һәм 7 пунктлары нигезендә тапшырылган документларны субсидияләр бирү соралган гаризаны теркәгән көннән алып 20 календарь көн эчендә түбәндәге очракларда кире кайтара:

документларны тулы комплекты тапшырылмаганда;

бюджет йөкләмәләре лимитыннан калган акчалар булмаганда.

9. Субсидияләрне күчерү Министрлык тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында һәм Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган хосусый счетыннан, исәп-хисап белешмәләренә нигезләнеп, Программада катнашучыларның исәп-хисап счетларына 5 эш көне эчендә башкарыла.

10. Бирелгән субсидияләр, субсидияләрнең максатчан билгеләнеше тотылмавы һәм (яки) субсидияләр алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булса, Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән алып алтмыш көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемен кире кайтарылырга тиеш.

11. Субсидияләр бирү турында килешүләрдә (шартнамәләрдә) каралган очракларда финанс хисабы елында тотылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемен субсидияләр алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

12. Әлеге Тәртипнең 10 һәм 11 пунктларында күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджеты керемен үз ирege белән кире кайтарудан баш

тартылган очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

13. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанас министрлыгы Программада катнашучыларга субсидияләр бирү бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшереп тора.

14. Программада катнашучылар тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә Программада катнашучыларга, аларның вазыйфаи затларына һәм җитәкчеләренә.

15. Бюджет акчаларының максатка ярашлы кулланылышын тикшереп торуны Министрлык гамәлгә ашыра.